РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 18 ноябре Кукмара ш. № 152

«Кукмара муниципаль районының 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына бюджеты турында» Кукмара муниципаль районы Советының 2021 елның 17 декабрендәге 92 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан тәкъдим ителгән 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Кукмара муниципаль районы бюджетына үзгәрешләрне карап, Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2022 елга Кукмара муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Кукмара муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 1 859 810 699,68 сум;

2) Кукмара муниципаль районы бюджетының гомуми чыгымнары күләме 1 905 586 983,26 сум;

3) Кукмара муниципаль районы бюджеты дефициты (профициты) 45 776 283,58 сум күләмендә.

2. 2023 елга һәм 2024 елга Кукмара муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Кукмара муниципаль районы бюджеты керемнәренең 2023 елга фаразлана торган гомуми күләмен 1 615 692 320,00 сум һәм 2024 елга 1 619 789 520,00 сум күләмендә;

2) 2023 елга Кукмара муниципаль районы бюджетының гомуми чыгымнары күләме 1 615 692 320,00 сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 14 264 100,00 сум һәм 2024 елга 1 619 789 520,00 сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 30 333 000,00 сум;

3) Кукмара муниципаль районының 2023 елга бюджет дефициты (профициты) 0 сум, 2024 елга 0 сум күләмендә.

3. Кукмара муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын түбәндәгечә билгеләргә:

2022 елга әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә;

2023 елга һәм 2024 елга әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә.»

1) 2022 елга Кукмара муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын карарга 1 нче кушымта нигезендә үзгәртергә.

2) 2022 елга Кукмара муниципаль районы бюджетының фаразланган керем күләмен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә үзгәртергә.

3) 2022 елга бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне карарга 3 нче кушымта нигезендә үзгәртергә.

4) 2022 елга Кукмара муниципаль районы чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә үзгәртергә.

5) 2022 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирлекләр бюджетларыннан алына торган бюджетара трансфертларны әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә үзгәртергә.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев